Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Нырья авыл җирлеге Советы

КАРАР

2021 елның 19 июле                                                                                   № 12

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру хакында һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Нырья авыл җирлеге Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Нырья авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2021 елның 30 июнен дә кертеп, **Нырья авыл җирлеге** Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 44 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче гражданнар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар анда билгеләнгәндә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә аларны биләгәндә муниципаль хезмәткәрләр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаларын биләүче гражданнар «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмә формасын формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча үзләренә, аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларына караган, бер үк вакытта цифрлы финанс активларын һәм башка цифрлы хокукларны, утилитар цифрлы хокукларны һәм цифрлы валютаны (булган очракта) үз эченә алган цифрлы финанс активлары, цифрлы хокуклар турында хәбәрнамәләр тапшырырга тиеш, дип билгеләргә.

2. **Нырья авыл җирлеге** Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 37 номерлы карары белән

расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу, пай өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.»;

3. **Нырья авыл җирлеге** Советының 2017 елның 11 сентябрендәге 18 номерлы карары белән расланган белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Нырья авыл җирлеге** муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү тәртибе турында Тәртипкә, 3 нче пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.».

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек Башлыгы: В.В.Васильев